ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.7, пос. Октябрьский,
422580

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 7 нче йорт, Октябрҗский авылы,
422580

Тел.: (84379) 31-4-27, факс: (84379) 31-4-27.

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылы гражданнары
җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

№4 25.11.2023

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылында 2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге составына керүче Ключищи авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны:

- Ключищи авылында авыл юлларына чокыр ремонты ясау;

- Су башнясын урнаштыруга юллау, - дигән мәсьәлә буенча 2023 елның 25 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 129 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 82 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

- «Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 82 кеше тавыш бирде;

- «Юк» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде

- җыенның 0 катнашучысы тавыш бирүдән тыелып калды.

Түбәндә бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылында гражданнар җыены узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылында 2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге составына керүче Ключищи авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны:

- Ключищи авылында авыл юлларына эчендә чокыр ремонты ясау,

- Су башнясын урнаштыруга юллау, - дигән мәсьәлә буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылы гражданнары җыены нәтиҗәләрен Октябрьский авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Ш.Р. Азизов